Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Богородский авыл җирлеге Советы

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Богородский авыл җирлеге башлыгы
КАРАРЫ

26 сентябрь, 2022 ел № 10

Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлеге Камыш торак пунктларында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 һәм 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлеге уставының 23 статьясы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Богородский авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда (торак пункт территориясе өлешендә) гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә нигезендә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кибәч авыл җирлеге Советының 2019 елның 08 ноябрендәге 164 номерлы карары (2021 елның 13 декабрендәге 39 номерлы карары белән расланган үзгәрешләр белән) нигезендә карар бирәм:

1. Богородский авыл җирлеге Камыш торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләргә:

Халык җыенын өч этапта үткәрергә:

- Халык җыенының беренче этабы 2022 елның 9 октябрендә 12 сәгать 00 минутта Яшел урамы, 2 йорт адресы буенча урнашкан тукталыш павильоны янында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Газовиклар урамы, Ларин урамы, Төзүчеләр урамы, Күләгәле урамы буенча теркәлгән кешеләрне кертергә;

- Халык җыенының икенче этабы 2022 елның 9 октябрендә 14 сәгать 00 минутта Яшел урамы, 2 йорт адресы буенча урнашкан тукталыш павильоны янында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Каен урамы, Заречная урамы, Камыш урамы, Якты урамы, Энергетиклар урамы, Җиләкле урамы буенча теркәлгән кешеләрне кертергә;

- Халык җыенының өченче этабы 2022 елның 9 октябрендә 16 сәгать 00 минутта Яшел урамы, 2 йорт адресы буенча урнашкан тукталыш павильоны янында

үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Дача урамы, Яшел урамы, Яшел алан урамы буенча теркәлгән кешеләрне кертергә.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Сез 2023 елда Богородский авыл җирлеге Камыш торак пункты территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары бер тапкыр бирелә торган түләүләрен (үзара салымын) түләүдән азат ителүе белән яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен куллану белән килешәсезме?:

- балалар мәйданчыгы төзү

«РИЗА» «КАРШЫ».

2. Әлеге карарны «Вперед» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Богородский авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Питрәч муниципаль районы
Богородский авыл җирлеге башлыгы М.Н. Бикбов

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН ПЕСТРЕЧИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «БОГОРОДСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
СОВЕТ БОГОРОДСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1633000835